**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево 422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевскийурамы, 23нчейортЛаешш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

**2021елның 15 декабре** **3911 номер**

**КАРАР**

**Лаеш шәһәре, Горький ур., 70 нче йорт адресы буенча урнашкан муниципаль милектәге 16:24:170138:13 кадастр номеры булган җир кишәрлекләрен межалау проектын әзерләү турында**

Территорияләрне тотрыклы үстерүне тәэмин итү, шул исәптән планлаштыру структурасы элементларын бүлеп бирү, җир кишәрлекләре чикләрен билгеләү, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 41, 43, 45 статьялары нигезендә капиталь төзелеш объектларын планлаштырып урнаштыру зоналары чикләрен билгеләү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставына таянып, КАРАР ИТӘМ:

1. Кадастр номеры 16:24:170138:13 булган җир кишәрлеген ызанлау проектын әзерләүгә керешергә. Адресы: Лаеш ш., Горький ур., 70 й.
2. Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 43 статьясы нигезендә проектның эчтәлеген билгеләргә.
3. Гавами тыңлаулар (иҗтимагый фикер алышулар) уздыруны исәпкә алып проектны әзерләү срогын 2021 ел ахырына кадәр билгеләргә.
4. Әлеге карар басылып чыкканнан соң ундүрт көн эчендә физик һәм юридик затларга территорияне межалау проектының тәртибе, сроклары һәм эчтәлеге турында тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетына җибәрергә тәкъдим итәргә.
5. Әлеге проектны әзерләү эшләрен оештыруны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура бүлегенә йөкләргә.
6. Әлеге карарны “Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

**Җитәкче** **А.А. Новиков**